**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Усады , ул.Советская, 41

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы, Совет ур.41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 ноябрь 2018 ел** **№ 153**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56, 56 статьялары нигезендә Биектау муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләренең беренче нөсхәләре нигезендә Җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, 2018 елның 18 ноябрендә узган мәсьәлә буенча:

“2019 елда ел саен 18 яше тулган һәр кешегә 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме?”.

Үзара салым акчасы тотылучы төзекләндерү чаралары исемлеге:

- Талмачи,Тимофеевка авылында балалар мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү;
- торак пунктында посёлок эчендәге юлларны ремонтлауга;
- Усад,Чубарово,Тимофеевка торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуга;

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1807 референдумда катнашучы кертелгән;

Референдумда катнашучылар саны 1041, бу 57,61 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 873 кеше тавыш бирде, бу 83,86 процент тәшкил итә;

«Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 156 кеше тавыш бирде, бу 14,99 процент тәшкил итә.

**КАРАР БИРДЕ:**

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдумны узган дип танырга.

2.Әлеге карарны Усад авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча халыкка игълан итәргә: http:// vysokaya-gora.tatarstan.ru,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы О.А.Фомин